Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«24» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге Рус Богдашкиносы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, балачактан инвалид булганнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Авыл җирлеге торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм таш түшәү (сатып алу, ташу, җәю).

Халык җыены рәисе: А. Л. Михайлова

Богдашкино авыл җирлеге башлыгы А. Л. Михайлова